ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
"ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ"

# ЭШ ПРОГРАММАЛАРЫН ТӨЗҮ БУЕНЧА МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
7НЧЕ СЫЙНЫФЛАРЫ ӨЧЕН
"ТАТАР ТЕЛЕ" ҺӘМ "ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ" ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА
ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Казан
2017

ББК 74.268.1Тат+74.268.3Тат
Э98

ТРМҮИ Гыйльми советы карары нигезендә бастырыла

ТРМҮИ ректоры Р.Р. Бәдриеваның гомуми редакциясендә

**Төзүче-авторлар:**

Мөхәрләмова Г.Н., филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар телен һәм әдәбиятын укытуның хәзерге проблемалары бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре

Гыйләҗева Л.Г., филология фәннәре кандидаты, Татарстан республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты

Вәлиева М.Н., Казан шәһәре Идел буе районының “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 10 нчы татар- рус урта гомуми белем мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Вәлиәхмәтова Г.М., Казан шәһәре Идел буе районының 18 нче татар гимназиясе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Әһлетдинова Л.Ф., Татарстан Республикасы “Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат” дәүләт автоном гомумбелем бирү учреждениесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Шәрипова Ч.Р., Татарстан Республикасы “Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат” дәүләт автоном гомумбелем бирү учреждениесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Акашина Н.М., Татарстан Республикасы, Казан шәһәре Яңа-Савин районы “Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 9 нчы урта гомуми белем мәктәбе” муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр. Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының 7нче сыйныфлары өчен «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» предметлары буенча эш программасы / төз.-авт.: Мөхәрләмова Г. Н. һәм башк. – Казан: ТРМҮИ, 2017. – 39 б.

"Татар теле" һәм "Татар әдәбияты" предметларының эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр "Россия Федерациясендә Мәгариф турында"гы Федераль законы, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның декабрендә чыккан 1577 номерлы боерыгы, федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә һәм гомуми белем бирүнең төп белем бирү үрнәк программаларын исәпкә алып эшләнде.

Методик тәкъдимнәрдә бирелгән материал белем бирү оешмалары җитәкчеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, методистлар өчен файдалы булачак.

© ТРМҮИ, 2017

# КЕРЕШ

Укытучы белән укучы арасындагы мөнәсәбәт Федераль дәүләт белем бирү стандартларында чагылыш таба. Укучылар белем алырга килә, ә укытучы укучыларның белем алуларын оештыра. Төп законнан алынган билгеләмәдә дә әлеге фикер ассызыклана: "Үз мәнфәгате һәм җәмгыять мәнфәгате өчен иҗади мөмкинлеген (потенциалын) тормышка ашырырга сәләтле; тормышта очраган кыенлыкларны җиңү юлларын мөстәкыйль табарлык, иҗади һәм фәнни фикергә ия; үзүсешкә сәләтле шәхес тәрбияләү". Моның белән бәйле рәвештә бүгенге көндә укыту процессын системалы-эшчәнлекле юнәлешкә ориентлашып алып бару, укучыларда федераль дәүләт белем бирү стандартларының бер таләбе булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыру алгы планга чыга. Һәр уку предметы аерым спецификага ия булып, үзенчәлекләр аның эчтәлегендә, планлаштырылган нәтиҗәләрендә дә чагылыш таба. Болар барысы укытучы төзегән эш программасында исәпкә алына.

Эш программасы – "педагог тарафыннан конкрет белем бирү оешмасы һәм билгеле бер сыйныф (төркем) өчен үрнәк программа нигезендә төзелгән, эчтәлегендә, темаларны өйрәнү эзлеклегендә, сәгатьләр санында, уку-укытуны оештыру формаларын куллануда һ.б. үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне үз эченә алган уку программасы ул"[1], икенче төрле әйткәндә, ул укытучының белем бирү эшчәнлеген оештыру системасын характерлый торган норматив-идарә итү документ.

Ул түбәндәге өлешләрдән тора: аңлатма язуы, уку предметының эчтәлеге, программаның бүлек һәм темаларны үз эченә алган календарь-тематик план, белем бирүнең планлаштырылган нәтиҗәләре, әлеге нәтиҗәләргә ирешүне бәяләү юллары һәм формалары. Гомуми белем бирүнең төрле баскычларында уку-укыту процессы әлеге программадан башка нәтиҗәле итеп оештырыла алмый.

Программаларны эшләү гомуми белем бирү оешмаларының уку-укыту, методик һәм норматив эшчәнлекнең аерылгысыз бер өлеше булып санала. Шул ук вакытта "Россия Федерациясендә Мәгариф турында"гы 273нче номерлы Федераль законы уку предметы, курсы, дисциплинасының (модуленең) эш программасы дигән төшенчәне үз эченә алса да, биредә әлеге төр программага куела торган таләпләр билгеләнми, шул сәбәпле укытучы эш программасын төзегән вакытта төрле характердагы сораулар белән очрашырга мөмкин.

Әлеге методик тәкъдимнәрдә әдәбият предметы буенча эш программасының моделен төзү буенча киңәшләр бирелә, эш программасының структурасы, төп өлешләре, аны төзү юнәлешләре билгеләнә.

Аерым уку предметы буенча төзелгән үрнәк программалар эш программасын төзүдә нигез булып тора, шуңа күрә аның билгеле параметрлары эш программасының структурын, өлешләрен төзүдә хезмәт итә.

Эш программасын төзегәндә аның максатларын, бурычларын һәм фукцияләрен истә тоту зарур.

Эш программасының төп максаты – уку-укытуның билгеле бер баскычында төп белем бирү программасын, планда каралган сәгатьләр санына туры килгән аерым уку предметы буенча үрнәк программаның эчтәлеген, дәрестән тыш эшләр планын, өстәмә белем бирү сәгатьләрен гамәлгә ашыру.

Эш программасының бурычлары булып:

- Уку йортының белем бирү эшчәнлеге максатлары, бурычлары һәм укучыларның үзенчәлекләрен исәпкә алып аерым уку предметының эчтәлеген, күләмен, уку материалын өйрәнү тәртибен билгеләү;

[1] Журин А.А. Рабочая программа по учебному предмету: разработка, экспертиза, утверждение: пособие для учителей и руководителей образовательных учреждений общего образования. – М.: Вентана-Граф, 2013. – Б. 14.

- Сыйныфтан сыйныфка күчкәндә программа эчтәлегенең дәвамчанлыгын тәэмин итү;
- Белем бирү оешмасының билгеле бер шартларын, уку ихтыяҗларын һәм укучыларның үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, педагогик эшчәнлекнең индивидуальлеген чагылдыру тора.

Эш программасының төп **функцияләре:**

- Норматив (эш программасы тулы күләмдә эшләнергә тиеш булган документ);
- Билгеле бер максатка ирешүне күздә тоту (эш программасы теге яки бу белем бирү өлкәсендә нәтиҗәгә ирешү өчен уку кыйммәтләрен һәм максатларын билгели);
- Эчтәлекле (эш программасы укучылар тарафыннан үзләштерергә һәм танып-белергә тиеш булган уку элементларының эчтәлеген, шулай ук аларның авырлык дәрәҗәсен билгеләүне күздә тота);
- Процессуаль (эш программасы эчтәлек элементларын үзләштерүнең логик эзлеклелеген, уку-укытуны оештыру формаларын, методларын, чараларын һәм шартларын, шулай ук уку-укыту процессының әлеге предмет буенча дәвамчанлыгын билгели);
- Бәя бирүче (эш программасы эчтәлек элементларын үзләштерүнең дәрәҗәсен, контрольгә алынучы объектны, контроль төрләрен һәм укучыларны бәяләү критерийларын ачыклый).

Аерым уку предметы буенча эш программасы РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның декабрендә чыккан 1577 номерлы боерыгы буенча эш түбәндәге өлешләрдән торырга тиеш:

1) аерым уку предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;
2) дәресләрне оештыру формаларын, укучыларның төп эшчәнлек төрләрен күрсәткән аерым уку предметының эчтәлеге;
3) һәр теманы үзләштерүгә бүлеп бирелгән сәгатьләрне күрсәткән календарь-тематик план.

Аерым уку предметы буенча эш программасын килештерү һәм раслауның тәртибе гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГОМУМИ ТӨП ҺӘМ УРТА БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕ (VII СЫЙНЫФ) ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татар теле. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Н.В.Максимов, Г.Ә.Нәбиуллина - Казан: Татар кит. нәшр., 2014– 159 б. дәреслеге буенча

**Төзүче-авторлары:** Вәлиева М.Н., Казан шәһәре Идел буе районының “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 10 нчы татар- рус урта гомуми белем мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Вәлиәхмәтова Г.М., Казан шәһәре Идел буе районының 18 нче татар гимназиясе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

**Программа түбәндәге хокукый-норматив документларны исәпкә алып төзелде:**

7 нче сыйныфлар өчен татар теленнән эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”);
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан “Об образовании” № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8);
3. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халыклары телләре турында”гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998);
4. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 (“Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – начального общего, основного общего и среднего общего образования”);
5. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.) “О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан”);
6. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы, 2004 нче ел, 1нче июль;
7. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы”, 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар;
8. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011 нче елның 1 нче февралендә теркәлгән);
9. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында “Дәүләт программасы”;
10. Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү концепциясе (2015-2030 нчы еллар).

7 нче сыйныф өчен “ Татар теле” курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыклары тарафыннан расланган үрнәк программа (“Татар

телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа", V – IX сыйныфлар өчен, Г. Р.Галиуллина, М.М.Шәкүровалар авторлыгында, 2013 ел) һәм 7 нче сыйныф өчен Н.В.Максимов, Г.Ә.Нәбиуллина эшләгән (Казан, Татар. кит. нәшр.; 2014) Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Татар теле. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Н.В.Максимов, Г.Ә.Нәбиуллина - Казан: Татар кит. нәшр., 2014. – 159 б.

## УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ УКЫТУ ПЛАНЫНДА ТОТКАН УРЫНЫ

Гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәбенең 7 нче сыйныфында ана теленнән белемнәр киңәйтелә. Татар телен укыту 6 нчы сыйныфта концентрик юнәлештә оештырыла, ягъни башлангыч сыйныфлардагы укыту предметының эчтәлеге тирәнәйтелеп кабатлана. 7 нче сыйныфта ФДББСның базис укыту планы буенча татар теле укытуга сәгатьләр саны түбәндәгечә каралган: атнага 2 сәгать. Барысы 70 сәгать.

Гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәбендә ана телен өйрәтү телнең төрле катламнарына караган теоретик материалны өйрәтү белән бергә, татар теленең сүзлек байлыгын, мәгънәви һәм кулланылыш үзенчәлекләрен камил куллана белергә, ана теленең сыгылмалылыгын, аралашу процессында ачыла торган нечкәлекләрен, үзенчәлекләрен өйрәтүне дә күздә тота. Татар мәктәпләрендә татар теленнән белем бирүнең нәтиҗәлелеген, сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уятуны һәм иң мөһиме — аңлап, дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, логик фикерләргә өйрәтүне, заманча технологияләрне файдаланып, телнең психолингвистик үзенчәлекләренә, мәдәният белән бәйләнешенә игътибар бирүне дә таләп итә. Бүгенге җәмгыятьтә барган үзгәрешләр ана телен укытуга яңа таләпләр куя. Беренче чиратта, ана теле дәресләре тел системасын, аның үзенчәлекләрен күзаллаган, милли үзаңга ия, милли менталитетны һәм психологияне аңлаган, заман таләпләренә җавап бирерлек күпкырлы шәхесләр тәрбияләүгә юнәлгән булырга тиеш. Әлеге таләпләр уку-укыту методикасын яңартуны, белем бирүгә яңача якын килүне, хәзерге җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең бала психологиясенә тәэсирен аңлауны һәм шулар нигезендә укыту эчтәлеген яңарту, уку-укытуның яңача алымнарын эзләү бурычын куя. Икенчедән, гомуми урта белемнең һәр ике баскычына нәтиҗә буларак кулланыла торган Бердәм республика имтиханына куелган таләпләр дә ана теленнән белем бирү эчтәлеген үзгәртү мәсьәләсе өлгереп җиткәнен күрсәтә.

Гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән тәкъдим ителгән үрнәк программа Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп эшләнде. Биредә гомуми төп белем бирү эшчәнлегенең формалашуы һәм үсеше программасында каралган төп идеяләр игътибарга алынган, татар мәктәпләренең башлангыч сыйныфларында ана теле укытуның гомуми үрнәк программасының эчтәлегендә каралган материалның дәвамчанлыгы һәм башлангыч белем бирү баскычында формалаша башлаган күнекмәләрнең үсеше каралган. Шулай ук төп белем бирү баскычында үзләштерелергә тиешле материалның эчтәлеге, укучыларның яшь һәм психологик үзенчәлекләре дә исәпкә алынган.

Үрнәк программада ана телен укытуның төп, мәҗбүри эчтәлеге бирелә. Әлеге программа нигезендә укыту эшчәнлегенең вариатив өлешен тәшкил иткән авторлык һәм эш программалары төзелә.

## 7 нче сыйныфта татар теленнән белем бирү максатлары

1. Укучыларның башлангыч мәктәптә фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү.
2. Укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү.
3. Телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү.
4. Татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белергә өйрәтү, сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен аңлату.
5. Баланың үзен тәрбияләү, үзе белән идарә итү, үз фикерен яклый алу сәләтен үстерү.
6. Укучының үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү.
7. Җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләренә, әхлак нормаларына төшендерү.
8. Укучыларның башлангыч мәктәптә фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү.
9. Телнең милли мәдәниятнең чагылышы булуын, тел һәм тарих бердәмлеген аңлату, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлегенә төшендерү; татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү.

## 7 нче сыйныфта татар теле укытуның төп бурычлары

1. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
2. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
3. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
4. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларның логик фикерләү сәләтләрен үстерү.
6. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

## 7 сыйныфта татар теленнән үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр

### Формалаштырылган осталык һәм күнекмәләр (уку елы башына):

- өйрәнелгән сүз төркемнәрен һәм аларның үзенчәлекле грамматик билгеләрен аера белү, сүз төркемнәрен морфологик яктан тикшерү;
- теоретик материалларга туры килгән орфограммаларны табу, сүзләрнең дөрес әйтелешен һәм язылышын үзләштерү; телдән һәм язма сөйләмдә ярдәмче фигыльләрне һәм синонимнарны файдалана белү; төрле сүз төркемнәренә кергән сүзләрне дөрес басым белән әйтә белү; тексттагы саннарны дөрес язу;
- бирелгән темага план төзеп, аның буенча сочинение язу өчен, материал туплау һәм тәртипкә китерү;
- сыйфатлама, хикәяләү һәм хөкем йөртү кебек сөйләм төрләренә туры китереп, сочинение язу, монологик һәм диалогик сөйләм формаларын үстерү;
- тормыштан алынган нинди дә булса бер вакыйга турында мәкалә язу;
- изложение яки сочинениеләрне тулыландыру, төзәтү;
- эш кәгазьләреннән расписка һәм акт яза белү.

**Укучылар үзләштерергә тиешле осталык һәм күнекмәләр (уку елы ахырына):**

- ел дәвамында өйрәнелгән синтаксик күренешләрне җөмлә һәм текст эчендә танып, аларга аңлатма бирү;
- төрле калыптагы гади җөмләләр төзү (ике яки бер составлы җөмләләр, ендәш һәм кереш сүзле җөмләләр, тиңдәш кисәкле яки аерымланган иярчен кисәкләре, гомумиләштерүче сүзләре булган җөмләләр), аларны язма сөйләмдә урынлы файдалану, телдән сөйләмдә дөрес интонация белән уку (әйтү);
- “гади җөмлә синтаксисы”нда өйрәнелгән тыныш билгеләрен язмада дөрес кую;
- сыйфатлама, эмоциональлек, модальлек элементларын кертеп, әдәби образларга характеристика яза белү;
- сөйләм этикеты нормаларына туры китереп, әсәргә яки геройлар арасындагы мөнәсәбәткә телдән яки язмача бәя бирү;
- эш кәгазьләреннән гариза яза белү.

**Предметны үзләштерүнең шәхескә кагылышлы, метапредмет, предмет нәтиҗәләре**

Икенче буын стандартларының нигезен яңа төр мөнәсәбәтләр тәшкил итә: бүген укучының билгеле бер белем дәрәҗәсенә ия булуын дәүләт кенә түгел, ә бәлки укучы, аның әти-әнисе дә дәүләттән билгеле бер күләмдә сыйфатлы белем бирүен таләп итү хокукына ия.

Икенче буын стандартлары шәхес үсешен тәэмин итү, укытуга үз эшеңне төптән белеп якын килү бурычын куя. Башкача әйткәндә, мәгариф системасы баланы белемле итү хакында гына түгел, аңа күнекмәләр бирү, аны эшкә өйрәтү турында да кайгырта.

Нәтиҗәләргә таләпләр – гомуми белем программаларының барлык төрләренең состав өлеше. Алар шәхескә кагылышлы, метапредмет (эшчәнлекнең гомумиләштерелгән ысуллары) һәм предмет буенча (фәнне өйрәнү) нәтиҗәләрне үз эченә ала.

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр**

Гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәбенең 7 нче сыйныфында ана теле предметын өйрәтү тел берәмлекләрен таный, аңлый һәм анализлый белү күнекмәләре белән бергә, сөйләм культурасын үстерүне, төрле типтагы һәм жанрдагы мәгълүматны үзләштерүне, аларны, сөйләм ситуациясенә һәм торенә карап, дөрес, төгәл итеп башкаларга җиткерә алуны, татар теленең әдәби һәм сөйләм әдәбе нормаларын күз алдында тота.

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- татар теленең татар халкы өчен төп милли-мәдәни кыйммәт булуын, ана телендә шәхеснең әхлакый, рухи һәм иҗади яктан формалашудагы ролен аңлау;
- туган телгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләре тәрбияләү, туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләргә теләк, омтылыш уяту;
- туган телдә аралашу, үз фикереңне һәм хисләреңне төгәл, анык, күпьяклы итеп белдерү өчен кирәкле булган сүзлек составын һәм грамматик, стилистик чараларны белү;
- белем ала белү, тел белеме өлкәсендә белемнәрне мөстәкыйль рәвештә үзләштерү, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыра белү;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;
- аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сөйләмне куллана һәм үзара бәйли белү;
- иптәшләренең сөйләменә игътибар итү, үзеңнең сөйләмеңә күзәтеп бәя бирү, хаталарны төзәтү, бәхәстә катнашу, төрле дәлилләр кулланып, тема буенча фикер алышу;
- индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру.

## Метапредмет нәтиҗәләр

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре (ТБУУГ):**

- танып-белү юнәлешендәге максатларны билгеләү;
- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә теманы, куелган проблеманы ача белү, фикер йөртү;
- уку мәсьәләсе тирәсендә логик фикерләү;
- фикерләүдә логик чылбыр төзү;
- тел берәмлекләрен сөйләм эшчәнлегендә дөрес һәм урынлы файдалана белү, язма сөйләм процессында орфография һәм пунктуация кагыйдәләрен үтәү;
- тема тирәсендәге төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү.
- үзеңнең белем системасында ориентлаша белү;
- телне әдәбият, тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ):**

- тыңлый белү;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен дәлилли белү, тормыштан мисаллар китерү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда, үзара хезмәттәшлек итүдә инициатива күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау, фикер әйтү, автор фикере белән чагыштыру;
- үз эшен контрольдә тоту, сыйныфташларына ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача житкерә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре (РУУГ):**

- дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын мөстәкыйль формалаштыру;
- проблеманы аңлап гипотеза чыгару, үз фикереңне дәлилләр китереп раслый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру; соңгы нәтиҗәне күздә тотып арадаш максатлар эзлеклелеген ачыклау;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, үзконтроль.

**Предмет буенча нәтиҗәләр:**

- 6 нчы сыйныфта өйрәнгән мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәрен, сүзләрнең ясалыш ягыннан төрләрен хәтердә яңарту, аларга хас закончалыкларны тирәнәйтү;
- сөйләмдә сүзләр бәйләнешен , җөмлә төрләрен, җөмлә кисәкләрен (баш кисәкләр, иярчен кисәкләр, модаль кисәкләр) өйрәнү;
- укылган текстның эчтәлеген аңлау, үз мөнәсәбәтләрен белдерү, укылган текстка бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү, тәкъдим ителгән темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү.

## Программаның төп эчтәлеге

| **№** | **Төп темалар** | **70** |
|---|---|---|
| 1 | Морфология бүлеген искә төшерү. Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Ярдәмлек сүз төркемнәре. Сүз төркемнәренең җөмлә төзүдәге роле. Сүз төркемнәренең җөмлә кисәге буларак функциясе. Сүзләрнең ясалыш ягыннан төрләре. Гади җөмлә синтаксисы. Синтаксик берәмлекләр. | 5 |
| 2 | Сөйләмдә сүзләр бәйләнеше. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. Тезүле бәйләнеш. Тиңдәш кисәкләр арасындагы теркәгечле һәм теркәгечсез бәйләнеш. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезүле бәйләнешне барлыкка китерүче чаралар. Тиңдәш кисәкләр арасына куела торган тыныш билгеләре. Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр. Гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләре. Ияртүле бәйләнеш. Ияртүле бәйләнештәге сүзләр арасында урнашкан хәбәрлекле, ачыклаулы, аныклаулы мөнәсәбәт. Ияртүле бәйләнештә ияртүче һәм ияртүче кисәк, аларның шартлы билгесе. Хәбәрлекле мөнәсәбәт; җөмләдә хәбәрлекле мөнәсәбәтне танып белү. Ияртүле бәйләнештәге сүзләр арасында ачыклаулы мөнәсәбәт. Ияртүле бәйләнештәге сүзләр арасында аныклаулы мөнәсәбәт. Аныклаулы мөнәсәбәткә керүче сүзләр янында тыныш билгеләре. Ияртүле бәйләнешне барлыкка китерүче чаралар. Синтаксик берәмлекләр. Сүзтезмә. Исем, фигыль, сыйфат, рәвеш, алмашлык, сан сүзтезмә. Хәбәрлек сүзтезмә. Сүзтезмәләрне тикшерү. | 27 |
| 3 | Җөмләләрне төркемләү. Җөмлә. Җөмлә турында төшенчә. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Ике составлы һәм бер составлы җөмлә турында төшенчә бирү. Бер составлы исем җөмлә һәм бер составлы фигыль җөмлә. Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре. Хикәя җөмлә. Сорау җөмлә. Сорау җөмләдә сүзләрнең урнашуы. Боерык җөмлә. Тойгылы җөмлә. Диалогик һәм монологик сөйләм формаларыннан файдалану. Синтагма. Сөйләмне синтагмаларга (мәгънәви кисәкләргә) бүлү. Сөйләмдә логик басымны дөрес билгеләү. Раслау һәм инкяр җөмләләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында төшенчә, аларның сөйләмдә роле. Тулы һәм ким җөмләләр, аларның әдәби һәм җанлы сөйләмдә роле. Гади һәм кушма җөмләләр. Гади җөмлә турында төшенчә бирү. Гади җөмләдә баш кисәкләрнең тиңдәшләнеп килүе. Кушма җөмлә турында төшенчә. Теркәгечле кушма җөмләләр. Теркәгечсез кушма җөмләләр. | 17 |
| 4 | Җөмләнең грамматик кисәкләре. Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм аның төрләре: гади ия, тезмә ия; аның җөмләдәге урыны. Хәбәр һәм аның төрләре: гади хәбәр, кушма хәбәр, аларның белдерелүе, аның җөмләдәге урыны. Җөмләнең иярчен кисәкләре, аларның мәгънәләре һәм сөйләм төзүдәге роле. Аергыч, аның белдерелүе, сораулары; җөмләдәге урыны. Тиңдәш һәм тиңдәш түгел аергычлар. Тәмамлык турында төшенчә, сораулары, җөмләдәге урыны. Туры һәм кыек тәмамлык, аларның белдерелүе, җөмләдәге урыны. Хәл. Вакыт, урын, рәвеш, күләм, сәбәп, максат, шарт һәм кире шарт хәле, аның белдерелүе, җөмләдәге урыны. Аныклагыч, аның белдерелүе, җөмләдәге урыны. Аныклагычларның аерымлануы, алар янында тыныш билгеләре. Аерымланган хәлләр. Аерымланган хәлләр янында тыныш билгеләре. Төрле хәлләрнең аерымлануы. Җөмләнең модаль кисәкләре. Кереш сүзләр, керешмәләр. Кереш җөмләләр. Кереш сүзләр һәм кереш җөмләләр янында тыныш билгеләре. Эндәш | 18 |

| | | |
|---|---|---|
| | сүзләр, алар янында тыныш билгеләре. Бер составлы җөмләләр. Сөйләмдә сүзләрнең туры һәм кире тәртибе. Инверсия. Җөмләнең грамматик кисәкләрен кабатлау**.** | |
| 5 | Синтаксик анализ. Ел буена үткәннәргә гомуми йомгак. | 3 |

**Бәяләү системасы**

**Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү**

Укучыларның тел һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен яки аларның гомуми грамоталылыгын диктант, изложение, сочинение, тест яздырып тикшереп була.

| Сыйныф | Диктант | Изложение | Сочинение | Тест |
|---|---|---|---|---|
| 7 | 6 (4) | 4 (2) | 4 (2) | 4 |

**Диктантларның күләме һәм аларны бәяләү**

Диктант – укучының гомуми грамоталылыгын тикшерү өчен уздырыла торган язма эшнең бер төре. Диктантлар берничә төрле була: сүзлек диктанты, өйрәтү диктанты, искәртмәле, аңлатмалы, сайланма, иҗади, күрмә, хәтер, ирекле диктантлар.

Орфографик хатасы булмаса, «5» ле куела (1 пунктуацион хата булырга мөмкин).

Бер орфографик, бер пунктуацион хатасы булса, «4» ле куела.

Ике орфографик, ике пунктуацион хатасы булса, «3» ле куела.

Биш орфографик, дүрт-алты пунктуацион хатасы булса, «2» ле куела.

**Сүзлек диктантының күләме һәм аны бәяләү**

| | |
|---|---|
| Сүз саны | 20-25 |

Сүзлек диктантына әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзләр, гарәп-фарсы алынмалары кертелә.

Пөхтә итеп язылган, хатасы булмаган эшкә «5» ле куела.

Бер орфографик хаталы эшкә «4» ле куела.

Өч орфографик хаталы эшкә «3» ле куела.

Биш орфографик хаталы эшкә «2» ле куела.

**Контроль диктантларның күләме һәм аларны бәяләү**

Алган белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен контроль диктантлар елга ике тапкыр яздырыла.

**Контроль диктантның күләме**

| | | | |
|---|---|---|---|
| Уку елы башында | 120 | Уку елы ахырында | 130 |

Контроль диктант текстлары өйрәнелгән темалар буенча орфограмма һәм пунктограммаларны (2-3 очрак) ала. Грамматик биремле диктант булганда, сүз саны киметелә дә ала. Контроль диктантта укучы тарафыннан төзәтүләр күп булса, билге бер баллга төшәргә мөмкин.

**Контроль диктантны бәяләү**

Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаса «5» ле куела. (1-орфографик, 2 пунктуацион хата булырга мөмкин.)

2 орфографик, 2 пунктуацион яки 1 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә «4» ле куела.

4 орфографик, 4 пунктуацион яки 3 орфографик, 6 пунктуацион хаталы эшкә «3» ле куела.

6 орфографик, 5 пунктуацион яки 5 орфографик, 8 пунктуацион хаталы эшкә «2»ле куела.

**Изложениенең күләме һәм аны бәяләү**

Изложение яздыру өчен, матур әдәбият әсәрләреннән өзекләр, хикәяләр, аерым текстлар алына. Алар эчтәлеге һәм күләме ягыннан тиешле сыйныф таләпләренә җавап бирергә, тәрбияви максатларны үз эченә алырга һәм бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, камилләштерү юнәлешендә булырга тиеш. Изложение ярдәмендә укучының тема эчтәлеген ача белү осталыгы, лексик байлыгы, орфография, грамматика, пунктуация өлкәсенә караган грамоталылыгы тикшерелә. Бу вакытта яңа сүзләр һәм тәгъбирләрне аңлатырга һәм аларны тактага язып куярга кирәк.

**Изложение текстының күләме**

| Уку елы башы | | Уку елы ахыры | |
|---|---|---|---|
| Сүз саны | Язма күләме | Сүз саны | Язма күләме |
| 200-300 | 120-130 | 300-350 | 130-140 |

**Изложениене бәяләү**

Изложениене бәяләгәндә, фикерләрнең логик эзлеклелегенә, эчтәлекнең тулы, дөрес бирелүенә, язма сөйләм теленең камиллегенә, грамоталы итеп яза алу дәрәҗәсенә игътибар ителә. Изложение һәм сочинениегә ике төрле билге куела. Берсе – эчтәлек, сөйләмне дөрес оештыра алу өчен, икенче – грамоталылыкка.

Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (1 орфографик, 2 пунктуацион яки 2 грамматик хатасы булырга мөмкин.)

Текстның эчтәлеге темага туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.

Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, 3 фактик, 2-3 техник хатасы булса, 3 орфографик, 4 пунктуацион, 2 грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.

Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела.

**Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү**

Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.) Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.

Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.

Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт-алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

**Сочинениенең күләме**

| Сыйныфлар | Бит саны | Сүзләр саны |
|---|---|---|
| 7 | 1.5-2 | 120-140 |

# КАЛЕНДАРЬ ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| Дәрес № | Дәрес темасы | Дәрес саны | Көтелгән нәтиҗә | | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контроль эш төрләре | Үткәрү вакыты план / факт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәхескә кагылышлы | метапредмет | предмет | | | |
| | | | | **Гади җөмлә синтаксисы. Морфология бүлегендә үткәннәрне искә төшерү** | | | | |
| **1** | Кабатлау. Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Ярдәмлек сүз төркемнәре | 1 | Укуга, ана теленә карата уңай мөнәсәбәт булдыру | **ТБУУГ:** схема буенча эшли белү, гомуми ысул кулланып, күнегүләр эшләү. **КУУГ:** әңгәмәдәш белән контакт урнаштырырга өйрәнү, сүзләрне дөрес һәм урынлы куллану. **РУУГ:** дәреснең темасын һәм максатын формалаштыру, үзбәяне дөрес куюга. ирешү | Сүз төркемнәрен таный һәм куллана белү. Сүз төркемнәренең шартлы билгеләре турында белемнәрне ныгыту | Телдән җаваплар, мөстәкыйль күнегүләр эшләү. Сүз төркемнәрен кабатлау | Мөстәкыйль эш | |
| **2** | Кабатлау. Сүз төркемнәренең җөмлә төзүдәге роле. Сүз төркемнәренең җөмлә кисәге буларак функциясе | 1 | Телнең әһәмиятен аңлау, милли горурлык хисләре формалаштыру | **ТБУУГ:** таблица нигезендә эшли белү, гомуми ысул кулланып, күнегүләр эшләү. **КУУГ:** парларда эшли белү, үз фикереңне дәлилләү. **РУУГ:** уку мәсьәләсен дөрес аңлауны бәяләү | “Сүз төркемнәре” һәм “Җөмлә кисәкләре” төшенчәсенең эчтәлеген белү | Телдән җаваплар, мөстәкыйль күнегүләр эшләү. Сораулар буенча төркемнәрдә эш. Терәк схема ясау | Мөстәкыйль эш | |
| **3** | Кабатлау. Сүзләрнең ясалыш ягыннан төрләре | 1 | Мөһим нәтиҗәләрне истә калдыру телəген үстерү, үз уңыш, уңышсызлыкларны гамәлгә күчерү | **ТБУУГ:** тексттан фактик мәгълүматны таба белү. **КУУГ:** фикерләрне дәлилләгәндә, төрле кагыйдәләрдән файдалана белү. **РУУГ:** эш нәтиҗәләрен бәяләү, үз фикереңне төгәл, тулы белдерү | Сүзләрнең ясалыш ягыннан төрләрен ныгыту. Сүзләрне ясалышлары ягыннан аера белү | Әңгәмә, күчереп язу, телдән җаваплар, күнегүләр эшләү | | |
| **4** | **Кереш диктант №1** | 1 | Үз-үзеңне бәяләү, үзанализга омтылыш булдыру | **ТБУУГ:** текстны кабул итү. **КУУГ:** алган белемнәрне төрле тел күренешләрен аңлатуда куллану. **РУУГ:** уңышка ирешү (ирешмәү) дәрәҗәсен аңлау, тикшерү | Алдагы сыйныфларда үзләштергән орфограммаларны язуда дөрес күрсәтә белү, грамоталы, чиста язу күнекмәсен камилләштерү | Диктант язу | Контроль дәрес. Диагностик диктант | |
| | | | | **Җөмләдә сүзләр бәйләнеше** | | | | |
| **5** | **Хаталар өстендә эш.** | 1 | Тел дәресләрендә | **ТБУУГ:** төрле билгеләрдән | “Синтаксис”, “Сүз”, | Диктантта | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Синтаксис турында төшенчә. Синтаксик берәмлекләр | | өйрәнгән белемне гамәлгә күчерү теләге булдыру, төркемнәрдә эшләү күнекмәсен камилләштерү | чыгып, төшенчә чыгару, укылган тексттан кирәкле мәгълүматны аерып алу. **КУУГ:** синтаксис буенча алган белемнәрне төрле тел күренешләрен аңлатуда куллану. **РУУГ:** индивидуаль эшне бәяли белү | “Сүзтезмә”, “Җөмлә” төшенчәләренең эчтәлекләрен белү. Сүзтезмә һәм тезмә сүзне аера белү | җибәрелгән хаталарны анализлау. Синтаксик берәмлекләрне аера белүгә телдән һәм язма күнегүләр эшләү | | |
| **6** | Сөйләмдә сүзләр бәйләнеше. Тезүле бәйләнеш. Тиңдәш кисәкләр арасындагы теркәгечле һәм теркәгечсез бәйләнеш | 1 | Белемле булуга омтылыш тудыру, телнең әһәмиятен аңлау | **ТБУУГ:** дәрестәге төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау. **КУУГ:** фикереңне төгәл, ачык әйтеп бирү, башкаларның фикерләрен дә исәпкә алу. **РУУГ:** уку мәсьәләсен дөрес аңлауны бәяләү | “Сөйләмдә сүзләр бәйләнеше”, “Тезүле бәйләнеш” төшенчәсенең эчтәлеген белү. Теркәгечле һәм теркәгечсез бәйләнешне аера белү | Тиңдәш кисәкләр, теркәгечләр, алар арасында тыныш билгеләрен кую буенча үтелгәннәрне кабатлау һәм күнегүләр эшләү | | |
| **7** | Тиңдәш кисәкләр арасындагы теркәгечле һәм теркәгечсез бәйләнеш | 1 | Дәрескә әзерлеккә үзбәя бирү, эшчәнлекнең максаты һәм нәтиҗәсе арасында бәйләнешне билгеләү | **ТБУУГ:** белем системасында ориентлаша белү. **КУУГ:** башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү. **РУУГ:** билгеләнгән критерийлар буенча үзбәя бирү | Теркәгечле һәм теркәгечсез бәйләнешне аера белү, бәйләүче чараларны куллана белү | Таблица өстендә эш | | |
Татар теле: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 7 нче сыйныфы өчен дәреслек / Н.В.Максимов, Г.Ә.Нәбиуллина - Казан: Татар кит. нәшр., 2014. – 159 б.

- Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: “Раннур”, 2000.
- “Татар теле. 5-11” интерактив дәреслеге (“Белем.ру” ҖЧҖ, 2009).
- Мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр: http://gzalilova.narod.ru/tatar_tele_deftere/6kl.html
- Эш кәгазе үрнәкләре: http://gzalilova.narod.ru/tatar_tele_deftere/e_k.html
- Терминнар сүзлеге: http://gzalilova.narod.ru/tatar_tele_deftere/s.html
- Анализ тәртибе: http://gzalilova.narod.ru/tatar_tele_deftere/a.html

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГОМУМИ ТӨП ҺӘМ УРТА БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕ (VII СЫЙНЫФ) ӨЧЕН ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Әдәбият. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 1 кисәк / Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова, Ф.Х. Җәүһәрова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 167 б.: порт. б-н.;

Әдәбият. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 2 кисәк / Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова, Ф.Х. Җәүһәрова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 191 б.: порт. б-н. дәреслеге буенча

**Төзүче-авторлары:** Әһлетдинова Л.Ф., Татарстан Республикасы “Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат” дәүләт автоном гомумбелем бирү учреждениесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Шәрипова Ч.Р., Татарстан Республикасы “Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат” дәүләт автоном гомумбелем бирү учреждениесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Акашина Н.М., Татарстан Республикасы, Казан шәһәре Яңа-Савин районы “Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 9 нчы урта гомуми белем мәктәбе” муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

### АҢЛАТМА ЯЗУЫ

7нче сыйныфлар өчен татар әдәбиятыннан эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

11. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”);
12. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан “Об образовании” № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8);
13. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халыклары телләре турында”гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998);
14. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 (“Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – начального общего, основного общего и среднего общего образования”);
15. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (Закон

Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.) “О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан”);

16. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы, 2004 нче ел, 1нче июль;

17. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы”, 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар;

18. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011 нче елның 1 нче февралендә теркәлгән);

19. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында “Дәүләт программасы”;

20. Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү концепциясе (2015-2030 нчы еллар).

7нче сыйныф өчен “Әдәбият” курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән “Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләренең 1-11 нче сыйныфлары өчен татар әдәбиятын укыту программалары” (Төзүче-авторлары: Ф.Г. Галимуллин, Ф.Ә. Ганиева, Д.Ш. Сибгатуллина). – Казан: Татар. кит. нәшр; 2011), 7 нче сыйныф өчен Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова, Ф.Х. Җәүһәрова эшләгән (Казан, Татар. кит. нәшр; 2014) Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Әдәбият. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 1 кисәк / Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова, Ф.Х. Җәүһәрова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 167 б.;

Әдәбият. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 2 кисәк / Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова, Ф.Х. Җәүһәрова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 191 б.

**7 нче сыйныфта татар балалары өчен әдәбият укытуның төп максаты**

- Татар әдәбиятының бай тарихын, классик язучыларының иҗатларын һәм иң күренекле әсәрләрне өйрәнү, үзләштерү;
- Әдәби төр, жанр, эчтәлек, форма һәм әдәби алымнар турындагы белемнәрне системага салу;
- Матур әдәбият әсәрләрен форма һәм эчтәлек берлегендә аңларга һәм анализларга өйрәтү;
- Иң күркәм әсәрләр мисалында рухи байлыкның кыйммәтен күрсәтү, аларның дәрәҗәсен күтәрү;
- Укучыда танып белү кызыксынуын уяту, белем алуга, иҗади һәм рухи үсүгә теләк – омтылыш тудыру, укучының иҗади сәләтен үстерү.

**Бурычлары:**

- Иҗат, әдәбият үсеше, аның тарихи төшенчәләрен, өйрәнелгән әдәби әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзалларга ярдәм итү;
- Матур әдәбият формалашуында һәм үсешендә зур роль уйнаган чәчмә һәм тезмә әсәрләр җыелмасы – халык авыз иҗаты, аның матур әдәбият белән уртак һәм аермалы якларын күрсәтү;
- Сәнгать әсәрен иҗат иткән әдипләргә карата хөрмәт уяту;

- Матур әдәбиятны милли һәм дөньякүләм культураның бер күренеше итеп карау, аның рухи кыйммәтләрне, традицияләрне саклаучы, тапшыручы икәнен аңлату;
- Әдәби әсәрне анализлау күнекмәләре булдыру, әдәбият теориясеннән 7 нче сыйныф программасы буенча теоретик белемнәр бирү һәм анализ барышында кулланырга өйрәтү;
- Әдәби әсәрдә тасвирланган тормыш вакыйгаларыннан үрнәк һәм гыйбрәт алырга, дөрес максатлар куярга өйрәтү;
- Әдәбиятның матурлыгын, хис-кичерешләр байлыгын күрсәтеп, балаларның рухи дөньясын баету;
- Укучыларда сөйләм культурасы булдыру һәм язма сөйләмне үстерү;
- Тормышта үз урынын табардай сәләтле шәхес тәрбияләү;
- Укучының мөстәкыйль фикерләвен, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясау сәләтен үстерү.

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- Өйрәнгән әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру
- Әдәби текстны кабул итү һәм анализлый алу, укыган буенча план төзи белү.
- Геройларга характеристика бирә алу.
- Әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыра белү, автор позициясен ачыклый алу.
- Укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерә алу, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку.
- Әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;
- Кеше образларын (төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар) күрә һәм аера белү;
- Жанр үзенчәлекләрен билгели белү;
- Әдәби әсәрдәге образлылык, образ, символ, деталь, аллегория, табигать образы, әйбер образы, пейзаж, портрет һ.б.ны күрә һәм аера белү;
- Комедия жанрын һәм аңа хас үзенчәлекләрне тану;
- Композиция: әсәр кору алымнарын күрә, аера белү;
- Тема, проблема, идея, пафос, сюжет элементларын һ.б. дөрес билгеләү.

**Күнекмәләргә таләпләр:**

- Сүз сәнгатенең образлы табигате турында күзаллау булдыру;
- Классик әдипләребезнең тормыш һәм иҗат юлларыннан төп фактларны белү;
- Өйрәнелгән төп әдәби-теоретик төшенчәләрне белү;
- Әдәби текстның сюжетын сөйли белү;
- Өйрәнелә торган әсәрнең аерым эпизодын (яисә күренешне) анализлый алу;
- Әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклый белү;
- Әдәби әсәрләрне чагыштыра белү;
- Әдәби әйтелеш таләпләрен саклаган хәлдә өйрәнелгән әсәрләрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- Өйрәнелгән әсәргә дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтеңне белдерү;
- Әсәрләргә телдән һәм язмача фикереңне белдерү, аларга бәя бирү;
- Диалогта яисә бәхәстә катнашу;
- Сүз сәнгатенең аерым күренешләре белән мөстәкыйль танышу һәм аларның эстетик кыйммәтен бәяләү (класстан тыш вакытта әсәр укуга ихтыяҗ булдыру);
- Татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү күнекмәсенә ия булу;
- Тәкъдим ителгән яки укучы үзе сайлаган әсәрләрне (шигырь, проза) яттан сөйләү.

**Уку фәненең уку планында тоткан урыны**

Уку елында 35 атна исәбе белән, әдәбият дәресләре атнага 2 сәгать укытылганда – 70 сәгать. Шуннан чыгып, әдәби әсәр укытуга - 58 сәгать, дәрестән тыш укуга – 4 сәгать, бәйләнешле сөйләм үстерүгә 8 сәгать вакыт бирелә.

Сөйләм үстерү дәресләрендә сочинение, образларга характеристика, әдәби әсәргә бәя язарга өйрәтү күздә тотыла.

**1. Уку предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- әдәбиятның кеше тормышындагы ролен билгели алу;
- үз халкыңның тарихы, мәдәнияте, әдәбияты белән горурлану хисләренә ия булу;
- милләткә мәхәббәт хисенең тирәнлеген, милләткә хезмәт итүнең бөеклегенә төшенү;
- әсәр геройлары үрнәгендә үзеңдә уңай сыйфатлар булдыру;
- янәшәдәге кешеләргә игътибарлылык, дусларга карата хөрмәт хисе булу, һөнәр турында җитди караш формалашу;
- әсәрдә гореф-гадәтләр һәм йолаларның бирелеше һәм аларга карата ихтирам хисләре булу;
- әсәргә салынган идеянең кыйммәтен кабул итү аша үз-үзеңне тәрбияләү;
- әдәби әсәрләр нигезендә әхлак тәрбиясе һәм патриотик тәрбия алу;
- әдәби әсәрләр үрнәгендә өлкән буынга ихтирамлы булу, гомумкешелек сыйфатларына ия булу;
- илебез азатлыгы өчен көрәшкән сугышчыларга хөрмәт хисенә төшенү, Ватаныбыз тарихына сакчыл карашлы булу;
- рухи байлыкның зур бәхет булуын аңлау.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

Әдәбиятны иҗтимагый һәм мәдәни тормыш-күренешләре белән бәйлелектә аңлау.

**Танып-белү гамәлләре:**

- гомум уку гамәлләре (танып белү мәсьәләсен аңлау, төрле жанрдагы текстлардан кирәкле мәгълүматны аерып чыгару, өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү, белемне структуралаштыру, нәтиҗәләр, гомумиләштерүләр ясау);
- логик уку гамәлләре (билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау, объектларны чагыштыру, классификацияләү критерийларын эшләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү);
- проблема кую һәм аны хәл итү (проблеманы тәгъбир итү, иҗади һәм эзләнү характерындагы проблемаларны хәл итү чараларын мөстәкыйль эшләү);

**Коммуникатив гамәлләр:**

- хезмәттәшлек итү;
- тел нормаларына туры китереп, монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булу;
- үз фикерләрен тәгъбир итү;
- текст эчтәлеген өлешләргә бүлеп сөйләү;
- фикерләрне дәлилләп җиткерү;
- сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү;
- фикерләрне эзлекле рәвештә, мисаллар белән дәлилләп, телдән һәм язмача формалаштыру;

**Регулятив гамәлләр:**

- уку мәсьәләсен кую;
- фаразлау;
- үз эшчәнлекне планлаштыру һәм оештыру;
- анализ барышын төзү;
- үзенең һәм башкаларның эшчәнлекләрен контрольдә тотып бәяли алу;
- үзанализ һәм үзбәя ясау.

**Предмет нәтиҗәләр:**

- халык авыз иҗаты – дастан жанрын үзләштерү, аның матур әдәбият белән уртак сыйфатларын һәм үзенчәлекләрен аера белү;
- әдәбият аша образлы фикерли алу;
- әдипләрнең тормышы һәм иҗаты турында мәгълүматлы булу, аларны истә калдыру;
- әдәби әсәрнең эчтәлеген белү, аңлау, төп фикерне таба белү;
- әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма берлегендә аңлый белү;
- әдәби әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләрен күрә һәм аера белү.
- автор позициясен ачыклый белү;
- әдәби әсәрләрнең кыйммәтен ачыклау, әдәбиятта тоткан урынын билгели белү;
- төп образларга бәя бирү алу;
- әдәбият теориясе буенча билгеле бер күләмдә теоретик белемгә ия булу.

# 2. КУРСНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

| № | Төп темалар | Сәгатьләр саны | Теманың кыскача эчтәлеге | Дәрес формасы | Төп эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Сәнгать төре буларак әдәбият | 1 | Әдәбиятның кеше тормышындагы роле. Сүз сәнгате буларак әдәбиятның үзенчәлекләре. Сүз сәнгатенә нигезләнгән башка сәнгать төрләре белән бәйләнеше | Дәрес-түгәрәк өстәл | Әдәбиятның кеше тормышындагы ролен билгеләү. Сәнгать турында гомуми күзаллау булдыру, сүз сәнгате буларак әдәбиятның үзенчәлекләрен билгеләү. Сүз сәнгатенә нигезләнгән башка сәнгать төрләре белән бәйләнешен ачыклау |
| 2. | Халык авыз иҗаты. “Идегәй” дастаны | 3 | Халык авыз иҗаты дастан жанры үзенчәлекләре. Дастан геройлары. Тарихи дастан “Идегәй” | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү | Дастан геройларының гамәлләренә бәя бирү. Тарихи дастан “Идегәй”не өйрәнү, образлар системасын анализлау |
| 3. | XX гасыр башы әдәбияты | 1 | XX гасыр башы әдәбиятында сүз сәнгатенең Шәрыкъ, рус һәм Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышлары | Дәрес-лекция | Чор үзенчәлекләре турында информация алу. Проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; план-конспект төзү |
| 4. | Г.Тукайның “Милләтә”, “Милли моңнар”, “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре | 3 | Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. “Милләтә”, “Милли моңнар”, “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре. Гражданлык лирикасы, автор позициясе төшенчәләре | Дәрес-презентация, дәрес-түгәрәк өстәл, дәрес-викторина | Укытучының сөйләвен тыңлау, шагыйрь иҗаты буенча хронологик таблица төзү. Шигырьләрне сәнгатьле уку; анализлау; фикерне раслау өчен, әсәрдән дәлилләр табу; сурәтләү алымнарын аеру. Шигъри текстларны яттан сөйләү |
| 5. | Н. Думави. “Яшь ана” | 3 | Н.Думавиның тормыш юлы һәм иҗаты. "Яшь ана" хикәясе. Әсәрнең идея-проблематикасы. Сәнгатьчә эшләнеше | Дәрес-эзләнү, дәрес-консультация, дәрес-проект | Хикәяне уку, анализлау, хис-кичерешләргә, геройларга бәя бирү, кеше образларын (төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар) күрсәтү. Сурәтләү чараларын табу, хикәянең үзенчәлекләрен билгеләү |
| 6. | Ш.Камал. “Акчарлаклар” | 3 | Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты. "Акчарлаклар" повесте. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Табигать образы. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә хронотоп | Дәрес-презентация, дәрес-түгәрәк өстәл | Әдәби текстны уку, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап табу, жанр үзенчәлекләрен билгеләү. Әдәби әсәрдәге образлылык, образ, символ, деталь, аллегория, табигать образы, әйбер образы, пейзаж, портрет һ. б.ны күрсәтү |
| 7. | 1920-1930 нчы елларда татар әдәбияты | 1 | Әдәби барышка тәэсир иткән тарихи вакыйгалар, аларның әдәбиятны каршылыклы үсешкә китерүе. Әдәби әсәрләрдәге төрлелек | Дәрес-лекция | Информацияне тыңлау, проблемалы сорауга җавап табу, план-конспект төзү |
| 8. | Һ. Такташ. “Мокамай” | 3 | Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗаты. "Мокамай" поэмасы. Лиро-эпик жанр буларак | Дәрес-презентация, дәрес-дискуссия | Поэманы уку, әсәрнең сюжет-композициясен тикшерү, образлар, хронотоп бирелешен |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | поэма. Эпиграф. Багышлау. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт | | билгеләү, тел-стиль ягыннан анализлау, идеяне чыгару |
| 9. | Г.Исхакый. “Җан Баевич” | 4 | Г.Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗаты. "Җан Баевич" комедиясе. Комедия жанры үзенчәлекләре | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес-диспут | Комедия жанрын һәм аңа хас үзенчәлекләрне тану, аеру. Әсәрне уку, эчтәлеген аңлау, фикер алышу, идеясен билгеләү |
| 10. | Г. Ибраһимов. “Кызыл чәчәкләр” | 4 | Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты. "Кызыл чәчәкләр" повесте. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре | Дәрес-лекция, дәрес-эзләнү, дәрес-дискуссия, сөйләм үстерү дәресе | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү. Әсәрне уку, сөйләү, проблемалы сорауларга мөстәкыйль җавап табу, геройларга бәя бирү. Әсәрнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү |
| 11. | XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты | 1 | XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә китергән тарихи сәбәпләрен ачыклау, бу чорда темаларның күп булуын, яңа иҗади агымнар, жанрлар турында гомуми күзаллау | Дәрес-лекция | Тыңлау, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, план-конспект төзү |
| 12. | С.Хәким. «Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» | 2 | С.Хәкимнең тормышы һәм иҗаты. «Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре. Күңел лирикасы жанры үзенчәлекләре, тел-стиль чаралары | Дәрес-презентация, интеграллашкан дәрес | Шигырьләрне сәнгатьле уку; анализлау; фикерне раслау өчен, әсәрдән дәлилләр таба алу; сурәтләү алымнарын аера белү. Шигъри текстларны яттан сөйләү |
| 13. | Ә. Еники. “Әйтелмәгән васыять” | 4 | Ә.Еникинең биографисе һәм иҗаты. “Әйтелмәгән васыять” повесте. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес-дискуссия | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү. Әсәрне уку, сөйләү, проблемалы сорауларга мөстәкыйль җавап табу, геройларга бәя бирү |
| 14. | Ш. Хөсәенов. “Әни килде” | 4 | Ш. Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗаты. “Әни килде” драмасы. Драма төренең драма жанры үзенчәлекләре. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, ретроспекция | Дәрес-презентация, дәрес-спектакль, дәрес-дискуссия, дәрес-суд | Драма жанрын һәм аңа хас үзенчәлекләрне тану, аеру. Әсәрне уку, эчтәлеген аңлау, фикер алышу, идеясен билгеләү, рольләргә бүлеп уку |
| 15. | Г. Сабитов. “Тәүге соклану”, “Ярсулы яз” | 3 | Г. Сабитовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Тәүге соклану”, “Ярсулы яз” хикәяләре. Композиция, тема, проблема, идея, пафос төшенчәләре | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү | Хикәяне уку, анализлау, хис-кичерешләргә, геройларга бәя бирү, кеше образларын (төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар) күрү һәм аеру. Сурәтләү чараларын табу, хикәянең үзенчәлекләрен билгеләп, төшенчә итеп чыгару |
| 16. | М. Мәһдиев. “Без – кырык беренче ел балалары” | 4 | М. Мәһдиевның тормыш юлы һәм иҗаты, “Без – кырык беренче ел балалары” повесте. Хикәяләүче, автор образлары, автор позициясе | Дәрес-презентация, дәрес-дискуссия, дәрес-эзләнү | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү. Әсәрне уку, сөйләү, проблемалы сорауларга мөстәкыйль җавап табу, геройларга бәя бирү. Әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләрен күрү, аеру |
| 17. | М. Галиев. “Уйна әле” | 2 | М. Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты. “Уйна әле” хикәясе. Әдәби әсәрдәге образлылык, тема, | Дәрес-презентация, интегралашкан дәрес | Укытучы сөйләвен тыңлау. Әсәрне уку, сөйләү, проблемалы сорауларга мөстәкыйль |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | проблема, идея төшенчәләре | | җавап табу, геройларга бәя бирү. Әсәр кору алымнарын күрүә һәм аеру. Тема, проблема, идея, вакыйга, күренеш, сюжет һәм аның элементларын дөрес билгеләү |
| 18. | Г. Гыйльманов. “Язмышның туган көне” | 3 | Г. Гыйльманов тормыш юлы һәм иҗаты. “Язмышның туган көне” хикәясе. Эчтәлек: вакыйга, конфликт, сюжет, сюжет элементлары төшенчәләре | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес-түгәрәк өстәл | Укытучы сөйләвен тыңлау. Әсәрне уку, өлешләп эчтәлеген сөйләү, проблемалы сорауларга мөстәкыйль җавап табу, геройларга бәя бирү. Вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, конфликт, сюжет һәм аның элементларын табу |
| 19. | З. Хәким. “Сәер кыз” | 3 | З. Хәкимнең иҗат биографиясе. “Сәер кыз” драмасы. Драма төренең драма жанр үзенчәлекләре, идея, тема, проблема. Сәнгати алымнар | Дәрес-презентация, дәрес-спектакль, интеграллашкан дәрес | Укытучының сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча чыгыш ясау. Драма жанрын һәм аңа хас үзенчәлекләрне табу. Әсәрне уку, эчтәлеген аңлау, фикер алышу, идеясен билгеләү. Драма әсәрен аңлы һәм сәнгатьле укый белү, укыганны телдән сурәтләп бирә алу. Сәнгатьчә эшләнешен тикшерү |
| 20. | Р.Харис. “Сабантуй” | 3 | Р.Харисның тормыш юлы һәм иҗаты. “Сабантуй” поэмасы. Жанр буларак поэма, лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр | Дәрес- презентация, дәрес-репортаж | Презентация карау, поэманы уку, анализлау, идеяне чыгару. Лирик һәм эпик төр сыйфатларның поэма жанрында чагылышын ачыклау. Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр турында фикер алышу |
| 21. | Р. Фәйзуллин. “Биеклек”, “Туган тел турында бер шигырь”, "Онытма син". | 3 | Р. Фәйзуллинның тормыш юлы һәм иҗаты. “Биеклек”, “Туган тел турында бер шигырь”, "Онытма син" шигырьләре. Лирик жанрлар | Дәрес-презентация дәрес-эзләнү, дәрес-дискуссия | Шигырьләрне сәнгатьле уку; анализлау; фикерне раслау өчен, әсәрдән дәлилләр таба алу; сурәтләү алымнарын аера белү. Шигъри текстларны яттан сөйләү |
| 22. | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 8 | Темалар:<br>"Милләтем – минем горурлыгым" (сочинение);<br>"Чын дус – сыналган дус" (сочинение);<br>"Әнием – бәгърем" (сочинение);<br>"Шинельле һәм шинельсез солдатлар" (сочинение) | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | Тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, иҗади эш башкару. Сочинение язу өчен план төзү, план буенча сочинениене мөстәкыйль язу |
| 23. | Дәрестән тыш уку | 4 | Г. Исхакый “Кәҗүл читек”<br>С. Хәким “Дәверләр капкасы” Хәзерге чор әдәбияты әсәрләре.<br>Вакытлы матбугатка күзәтү | Дәрестән тыш уку дәресе | Дәрестән тыш әдәби әсәрләр уку; аларның эчтәлеген сөйли алу; әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү; фикерне раслау өчен, әсәрдән дәлилләр таба алу |
| | | | Барлыгы: | 70 | |

**Татар мәктәбенең 7 нче сыйныфында укучы татар балаларына әдәбияттан тәкъдим ителә торган әсәрләр минимумы**

1. «Идегәй» дастаны (кыскартып).
2. Г.Тукай. «Милләтә» шигыре.
3. Н.Думави. «Яшь ана» хикәясе.
4. Г.Исхакый. «Җан Баевич» комедиясе (кыскартып).
5. Ш.Камал. «Акчарлаклар» повесте (кыскартып).
6. С.Хәким. «Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре.
7. Ә.Еники. «Әйтелмәгән васыять» хикәясе (кыскартып)
8. Г. Сабитов. «Тәүге соклану» хикәясе.
9. М.Мәһдиев. «Без кырык беренче ел балалары» повесте (кыскартып).

**Яттан өйрәнү өчен әсәрләр.**

1. “Идегәй” дастаны (өзек).
2. Г.Тукай. “Милли моңнар” шигыре.
3. Һ. Такташ. “Мокамай” поэмасы (өзек)
4. С. Хәким. “Әнкәй” шигыре.
5. Ш.Хөсәенов. “Әни килде” драмасы (бер монолог).
6. М. Мәһдиев. “Без - кырык беренче ел балалары” повесте (өзек).
7. Р.Фәйзуллин. “Туган тел турында бер шигырь” (өзек).

**3. Календарь-тематик планлаштыру**

| № | Дәрес темасы | Сәгатьләр саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1 | Сәнгать төре буларак әдәбият | 1 | | |
| 2 | Халык авыз иҗатының бер жанры буларак дастан | 1 | | |
| 3 | “Идегәй” дастаныныж идея-проблематикасы | 1 | | |
| 4 | “Идегәй” дастанының сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 5 | XX гасыр башында сүз сәнгате | 1 | | |
| 6 | Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. “Милләтә” шигыре | 1 | | |
| 7 | Г.Тукай. “Милли моңнар” шигыре | 1 | | |
| 8 | Г.Тукай. “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре | 1 | | |
| 9 | БСҮ. “Милләтем – минем горурлыгым” | 1 | | |
| 10 | БСҮ. “Милләтем – минем горурлыгым” | 1 | | |
| 11 | Н.Думавиның тормыш юлы һәм иҗаты. «Яшь ана» хикәясе | 1 | | |
| 12 | Н.Думави. «Яшь ана» хикәясендә күтәрелгән проблемалар | 1 | | |
| 13 | Н.Думави. «Яшь ана» хикәясенең сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 14 | Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты. «Акчарлаклар» повесте | 1 | | |
| 15 | Ш.Камал. «Акчарлаклар» повестеның идея-проблематикасы | 1 | | |
| 16 | Ш.Камал. «Акчарлаклар» повестеның сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 17 | 1920-1930 нчы еллар әдәбияты | 1 | | |
| 18 | Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗаты. “Мокамай” поэмасы | 1 | | |
| 19 | Һ.Такташ. “Мокамай” поэмасының идея-проблематикасы | 1 | | |
| 20 | Һ.Такташ. “Мокамай” повестеның сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 21 | Г.Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗаты. «Җан Баевич» комедиясе | 1 | | |
| 22 | Г.Исхакый. «Җан Баевич» комедиясендә күтәрелгән проблемалар | 1 | | |
| 23 | Г.Исхакый. «Җан Баевич» комедиясенең идея-проблематикасы | 1 | | |
| 24 | Г.Исхакый. «Җан Баевич» комедиясенең эшләнеше | 1 | | |
| 25 | ДТУ. Г.Исхакый. “Кәҗүл читек” | 1 | | |
| 26 | Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Кызыл чәчәкләр” повесте | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 27 | Г.Ибраһимов. “Кызыл чәчәкләр” повестенда образлар системасы | 1 | | |
| 28 | Г.Ибраһимов. “Кызыл чәчәкләр” повестеның идея-проблематикасы | 1 | | |
| 29 | Г.Ибраһимов. “Кызыл чәчәкләр” повестеның сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 30 | БСҮ. “Чын дус – сыналган дус” | 1 | | |
| 31 | БСҮ. “Чын дус – сыналган дус” | 1 | | |
| 32 | XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты | 1 | | |
| 33 | С.Хәким тормыш юлы һәм иҗаты. «Әнкәй» шигыре | 1 | | |
| 34 | С.Хәким. «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигыре | 1 | | |
| 35 | ДТУ. С. Хәким. “Дәверләр капкасы” поэмасы | 1 | | |
| 36 | Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗаты. «Әйтелмәгән васыять» повесте | 1 | | |
| 37 | Ә.Еники. «Әйтелмәгән васыять» повестенда образлар системасы | 1 | | |
| 38 | Ә.Еники. «Әйтелмәгән васыять» повестеның идея-проблематикасы | 1 | | |
| 39 | Ә.Еники. «Әйтелмәгән васыять» повестеның сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 40 | Ш.Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗаты. “Әни килде” драмасы | 1 | | |
| 41 | Ш.Хөсәенов. “Әни килде” драмасының идея-проблематикасы | 1 | | |
| 42 | Ш.Хөсәенов. “Әни килде” драмасының композиция үзенчәлекләре | 1 | | |
| 43 | Ш.Хөсәенов. “Әни килде” драмасында сурәтләү алымнары | 1 | | |
| 44 | БСҮ. “Әнием-бәгърем” | 1 | | |
| 45 | БСҮ. “Әнием-бәгърем” | 1 | | |
| 46 | Г. Сабитовның тормыш юлы һәм иҗаты. «Тәүге соклану» хикәясе | 1 | | |
| 47 | Г. Сабитов. “Ярсулы яз” хикәясе | 1 | | |
| 48 | Г. Сабитов хикәяләренең сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 49 | М.Мәһдиевның тормыш юлы һәм иҗаты. «Без кырык беренче ел балалары» повесте | 1 | | |
| 50 | М.Мәһдиев. «Без кырык беренче ел балалары» повестенда образлар системасы | 1 | | |
| 51 | М.Мәһдиев. «Без кырык беренче ел балалары» идея-проблематикасы | 1 | | |
| 52 | М.Мәһдиев. «Без кырык беренче ел балалары» идея-проблематикасы | 1 | | |
| 53 | М. Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты. “Уйна әле” хикәясе | 1 | | |
| 54 | М. Галиев. “Уйна әле” хикәясенең сюжет-композициясе | 1 | | |
| 55 | БСҮ. “Шинельле һәм шинельсез солдатлар” | 1 | | |
| 56 | БСҮ. “Шинельле һәм шинельсез солдатлар” | 1 | | |
| 57 | ДТУ. “Күп укыган – күп белгән” (Хәзерге чор әдәбияты белән танышу) | 1 | | |
| 58 | Г.Гыйльмановның тормыш һәм иҗат юлы. “Язмышның туган көне” хикәясе | 1 | | |
| 59 | Г.Гыйльманов. “Язмышның туган көне” хикәсендә күтәрелгән проблемалар | 1 | | |
| 60 | Г.Гыйльманов. “Язмышның туган көне” хикәясенең сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 61 | З.Хәкимнең иҗат биографиясе. “Сәер кыз” драмасы | 1 | | |
| 62 | З.Хәким. “Сәер кыз” драмасының идея-проблематикасы | 1 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 63 | З.Хәким. “Сәер кыз” әсәренең сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | | |
| 64 | Р.Харисның тормыш юлы һәм иҗаты. “Сабантуй” поэмасы | 1 | | | |
| 65 | Р.Харис. “Сабантуй” поэмасы | 1 | | | |
| 66 | Р.Харис. “Сабантуй” поэмасы. Татар халкының милли бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре | 1 | | | |
| 67 | ДТУ. Вакытлы матбугатка күзәтү ясау | 1 | | | |
| 68 | Р.Фәйзуллинның тормыш юлы һәм иҗаты. “Биеклек” шигыре | 1 | | | |
| 69 | Р.Фәйзуллин. “Туган тел турында бер шигырь” шигыре | 1 | | | |
| 70 | Р.Фәйзуллин. “Онытма син” шигыре. Йомгаклау | 1 | | | |

**Белем бирүнең укыту-методик һәм матди-техник яктан тәэмин ителеше**

Укытуны матди-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү нигезенә түбәндәгеләр керә:

- белем һәм тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килгән уку бинасы булу;
- әдәбиятны өйрәнү өчен җитәрлек күләмдә дәреслекләр һәм өстәмә методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән китапханә;
- электрон китапханә, башка электрон ресурслар, татарча сайтлардан куллану мөмкинлеге булган компьютер классы;
- электрон һәм басма күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр;
- мультимедиа укыту программалары, компьютер программалары;
- укучыларының белемнәрен тикшерү программалары;
- төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр;
- белешмә материаллар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
- интерактив тикшерү программалары;
- татар сайтлары

(http://www.tatarile.org.com, http://www.tatknigafund.ru/, http://miras.belem.ru/, http://gabdullatukay.ru/, http://gzalilova.narod.ru/adabiyat_deftere/7kl.html).

**Әдәбият исемлеге**

1. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1990
2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.
3. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009.
4. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009
5. Дастаннар. – Казан: Мәгариф, 2001.
6. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005.
7. Заһидуллина Д.Ф Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Яңадан эшләнгән һәм тулыландырылган басма. – Казан: Мәгариф, 2004.
8. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов А.М. Татар әдәбияты: Теория. Тарих.– Казан: Мәгариф, 2006.
9. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010.
10. Исламов Ф.Ф. Әдәби викториналар – әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүдә кыйммәтле чара. – Казан, 2005.
11. Йосыпова Н.М. XX гасыр татар шигъриятендә символлар. – Казан: Мәгариф, 2006.
12. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983 – 2001.
13. Татар әдәбияты. Теория.Тарих./Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Т.Гыйлаҗев, Н.Йосыпова. – Казан: Мәгариф, 2006.
14. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1977, 1979, 1981.

**Күрсәтмә материаллар**

1. Электрон ресурслар: “Бала” китапханәсе, “Татар мультфильмнары”, мультимедиа укыту программалары; электрон китапханә; татар сайтлары (belem.ru, tatarile.org.com); аудио һәм видео әсбаплар:
2. Габдулла Тукай. Интерактив мультимедиа уку-укыту әсбабы.
3. Габдулла Тукай. Энциклопедия. Дисклар коллекциясе.
4. «Габдулла Тукай», «Вамин» Татарстанның мәдәни традицияләрен саклау һәм үстерү фонды, DVD и 1 CD дан торган җыентык, 2009.
5. Классик әдәбиятыбыз үрнәкләре. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD 4 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
6. Шигърият бакчасында. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар) CD 1, CD 2, CD 3 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
7. Гаяз Исхакый. Тормышы һәм иҗатына багышланган методик әсбап. Мультимедиа басма.
8. Язучыларыбыз чыгышлары һәм алар турында истәлекләр. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD5 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
9. Язучылар, композиторлар һәм рәссамнар чыгышлары, алар турында истәлекләр. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD 6 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.

**ЭШ ПРОГРАММАЛАРЫН ТӨЗҮ БУЕНЧА**

**МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР**

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
7НЧЕ СЫЙНЫФЛАРЫ ӨЧЕН
"ТАТАР ТЕЛЕ" ҺӘМ "ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ" ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА
ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Печатается в авторской редакции

Форм. бум. 60x84 1/8. Гарнитура Times.
Усл.печ.л. 5

Институт развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
Сайт: irort.ru e-mail: irort2011@gmail.com